Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 19 декабрендәге 445-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, күчемсез милек объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү срокларын үзгәртә торган Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 09 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, реконструкцияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.4 п. пунктына «8 көн» сүзләрен «7 көн» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 09 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.4 п. пунктына «8 көн» сүзләрен «7 көн» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов